**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** 05.11.2024 | Казан ш. | **БОЕРЫК** 1229-п

Татарстан Республикасы территориясендә Урман Зәе елгасының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Урман Зәе елгасының яр сызыгы (су объекты чиге) өлешенең урнашу урынын билгеләү эшләрен уздыруга бәйле рәвештә, тапшырылган эш материаллары нигезендә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Урман Зәе елгасының су саклау зоналарының һәм яр буе саклык полосаларының киңлеген, әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып, түбәндәгечә билгеләргә:

су саклау зонасының киңлеге – 200 м;

яр буе саклагыч полосасының киңлеге: ярның кирегә яки нульгә авышлыгы булганда – 30 м, ярның 3 градустан кимрәк авышлыгы булганда – 40 м, ярның 3 градустан һәм аннан да күбрәк авышлыгы булганда – 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов):

2.1. дәүләт су реестрына кертү өчен Урман Зәе елгасының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында белешмәләрне Федераль су ресурслары агентлыгына җибәрергә;

2.2. территорияләренә карата су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләре билгеләнә торган муниципаль, шәһәр округы, җирлекнең җирле үзидарә органына белешмәләр җибәрергә;

2.3. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен, Урман Зәе елгасының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында белешмәләрне Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органына) җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В.Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (Р.А.Заһидуллин) әлеге боерыкны, теркәтү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевага йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков